**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

__________ __________

**Актаныш муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органнарын һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләү турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Авыл җирлекләрендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларда авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыру һәм терлекчелек тармагын үстерүне стимуллаштыру, авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыруга кызыксындыру, терлекчелек тармагын үстерү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органын һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләү турындагы нигезләмәне 1 нче кушымта нигезендә расларга.
2. Комиссия составын 2 нче кушымта нигезендә расларга.
3. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 17 маендагы ПР-89 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы — Л.Ф.Нурлыева

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
___________________№____
1 нче кушымта

ТР Актаныш муниципаль районы авыл җирлеге җирле үзидарә органын
һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләү турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Актаныш муниципаль районының җирле үзидарә органын һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләү, терлекчелек тармагының үсеш дәрәҗәсен күтәрүне стимуллаштыру, шәхси ярдәмче хуҗалыкларда терлекчелекне үстерү, районның терлекчелек тармагын үстерү дәрәҗәсен күтәрүне стимуллаштыру, авыл хуҗалыгы терлекләренең продуктивлыгын арттыру һәм республика дәрәҗәсендә югары күрсәткечләргә ирешү максатларында, ай саен, 24 форма йомгаклары буенча башкарыла.

1.2. Бүләкләү тантанасын гамәлгә куючы һәм оештыручы - Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты.

1.3. Бүләкләү акчалата формада башкарыла.

1.4. Финанслау район бюджеты хисабына башкарыла.

1.5. Бүләкләүдә катнаша алалар:

1.5.1. Авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары;

1.5.2. Крестьян (фермер) хуҗалыгы - КФХ, шәхси эшмәкәрләр – ИП, ачык акционерлык җәмгыятьләре – ААҖ, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр – ҖЧҖ, акционерлык җәмгыятьләре – АҖ, ябык акционерлык җәмгыятьләре – ЯАҖ, алга таба авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре.

2. Бүләкләү максатлары

2.1. Бүләкләү түбәндәге максатларда үткәрелә:

Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре тарафыннан авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүне арттыру;

- Актаныш районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең хуҗалык-финанс хәлен яхшырту;

- башкарылган эш өчен җаваплылыкны арттыру.

3. Авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләү тәртибе

3.1 Авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләү түбәндәге шартларны үтәгәндә башкарыла:

- узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда агымдагы айда 1 шартлы башка күбрәк акчалата керем алу;

- эре мөгезле терлекләр саны узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда ким түгел;

- бер сыерга сөт җитештерү узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда югарырак һәм уртача район күрсәткеченнән ким түгел;

- 1 баш мөгезле эре терлек ите җитештерү узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда югарырак һәм район буенча уртача күрсәткечтән ким түгел.

3 урын билгеләнә, авыл хуҗалыгы предприятиеләре акчалата бүләкләнә:

1 урын - 40000 (кырык мең) сум,

2 урын - 30000 (утыз мең) сум,

3 урын - 20 000 (егерме мең) сум.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1 п. күрсәтелгән бүләкләү өчен җибәрелгән акчалар 5 эш көне эчендә оешманың исәп-хисап счетына күчерелә.

3.2. Бүләкләнгән авыл хуҗалыгы предприятиесе җитәкчесе, 24-форма йомгаклары буенча, ирешелгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, терлекчелек предприятиеләре хезмәткәрләрен бүләкләүне оештыра. Бүләкләү беркетмәсе ТР Актаныш муниципаль районында ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе баш бухгалтеры тарафыннан тапшырыла.

3.2.1. Ай нәтиҗәләрен чыгарганда хуҗалыклар бер үк балл тупласалар, бер шартлы баш терлеккә акчалата керемнәре күбрәк булганнарга өстенлек бирелә.

3.3. Авыл хуҗалыгы предприятиесе хезмәткәрләрен бүләкләү беркетмәсен ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Актаныш муниципаль районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы 3 (өч) эш көне эчендә, беркетмә тапшырганнан соң таныклый.

## 4. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органын бүләкләү тәртибе

4.1. Авыл җирлеге җирле үзидарә органын бүләкләү түбәндәге шартлар үтәлгәндә башкарыла:

- алдагы айның күрсәткечләре белән чагыштырганда, түбәндәге күрсәткечләр: эре мөгезле терлекләр, сыерлар, сарыклар, кәҗәләр, атлар саны арткан;
- сөт сату, узган ай күрсәткечләре белән чагыштырганда, югарырак һәм республика буенча уртача күрсәткечтән ким түгел;
- сөткә бәяләре район буенча уртачадан ким түгел.

Комиссия тарафыннан җиңүче итеп сайлап алынган авыл җирлеге, бирелгән мәгълүматны карау нәтиҗәләре буенча, 10 000 (ун мең) сум күләмендә акчалата премия белән бүләкләнә.

Ай нәтиҗәләрен чыгарганда җирле үзидарә органнары бер үк төрле баллар җыйса, өстенлек алдагы ай күрсәткечләреннән югарырак булганына бирелә.

## 5. Җирле үзидарә органнарын һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләү буенча комиссия

5.1. Актаныш районы авыл җирлеге һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре бүләкләнүчеләрен билгеләү буенча комиссия төзелә (алга таба – комиссия) һәм аның составы раслана.

Комиссия составына түбәндәге затлар керә: комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре, комиссия әгъзалары.

- Комиссия рәисе комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, комиссия утырышларын үткәрә.
- Комиссия рәисе урынбасары комиссия рәисе вазыйфаларын ул булмаганда башкара.
- Комиссия секретаре комиссия әгъзаларына комиссия утырышының урыны, вакыты турында хәбәр итә, утырыш беркетмәләрен төзи, комиссия документларын формалаштыра.

5.2. Комиссия утырышы, әгәр анда комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары утырышларда алыштыру хокукы булмаган килеш катнаша. Комиссия әгъзасы утырышта була алмаган очракта, ул

карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә тапшырырга хокуклы. Бу очракта ул комиссия утырышында игълан ителә һәм утырыш беркетмәсенә теркәлә.

5.3. Комиссия карарлары комиссия составына керүче затларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, комиссия утырышында рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.4. Комиссия, комиссиягә тәкъдим ителгән әлеге Нигезләмәнең 3.1 һәм 4.1 пунктларында билгеләнгән ирешелгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән, бүләкләү өчен, авыл җирлеген һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен билгели. Иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән авыл җирлекләре һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре бүләкләнә.

5.5. Комиссия утырышында кабул ителә торган карарлар, комиссия утырышыннан соң икенче көнне комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзаланган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

## 6. Нәтиҗәләр ясау һәм бүләкләүне оештыру

6.1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге комиссия беркетмәсен алганнан соң, өч көн эчендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең авыл җирлеген һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен бүләкләүгә акча бүлеп бирү турындагы күрсәтмә проекты әзерләнә.

6.2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең күрсәтмә проектында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

оешма исеме;

җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булганда);

акчалата бүләк суммасы;

Актаныш муниципаль районы муниципаль программасының конкрет чарасын һәм бюджет классификациясе кодын күрсәтеп, финанслау чыганагы.

6.3. Бүләкләүгә бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуын, аларны күчерүнең дөреслеген һәм үз вакытында башкарылуын тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм фаразлау бүлеге гамәлгә ашыра.

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарына
__________________ №____
2 нче кушымта

ТР Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы предприятиеләренең терлекчелек хезмәткәрләре – зоотехниклар, ферма мөдирләре, ветеринария хезмәткәрләре, көтүлекләрне үрчетү буенча технологлар арасында бүләкләү һәм премияләүгә кандидатлар буенча комиссия составы

Комиссия рәисе:

1. Галимҗанова Р. Ф. - Актаныш муниципаль районы Башлыгы урынбасары (авыл җирлеген сайлап алу документларын караганда);
2. Сираева Л.Р. - Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары (а/х предприятиеләрен сайлап алу документларын караганда).

Комиссия әгъзалары:

1. Икътисад бүлеге башлыгы - Мирзашарипова О.М.
2. ТР Актаныш муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы-Сәлимгәрәев Н.Ә.;
3. Актаныш районы дәүләт ветеринария берләшмәсе башлыгы - Абдрахманов Ф.Ә.;
4. Яр Чаллы шәһәре (Актаныш авылы) Дәүләт статистикасы бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты - Вильданов Р.А.

Секретаре:

3. Авыл хуҗалыгы һәм азык–төлек идарәсенең өлкән белгече - Шаһиәхмәтова Г. З. (а/х предприятиеләрен сайлап алу буенча документларны караганда);
4. Советның оештыру бүлеге башлыгы урынбасары - Шәрәфиева Э.Д. (авыл җирлеген сайлап алу буенча документларны караганда).